**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.09.2024

г. Казань

№ 158од

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул итүнең 2023 елның 8 ноябрендәге 160од номерлы боерык белән расланган (2024 елның 26 февралендәге 29од номерлы боерык белән кертелгән үзгәреш белән) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшмәкәрнең банкротлык процедурасын тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә ул түләү бурычыннан азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;»;

2.3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Штраф рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турындагы актларны куллану яки суд тарафыннан аның нигезендә Министрлык бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган, шул

исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә дә, карар кабул итү;»;

2.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Суд пристав-башкаручының башкарма производствоны тәмамлау һәм «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кайтару турында карар чыгаруы, әгәр күләме бурычлыга карата банкротлык турында эш кузгату өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык вакыт узган булса;»;

түбәндәге эчтәлектәге $2.6^{1}$ пунктчаны өстәргә:

«$2.6^{1}$ Банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле суд тарафыннан бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны кире кайтару турында акт кабул итү»;

4 пунктның 4.3 пунктчасында:

дүртенче абзацта «2.3 пунктчасында» сүзләрен «2.2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «2.6 пунктчасында» сүзләрен «2.6, $2.6^{1}$ пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «2.6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «$2.6^{1}$ пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

Министр Р.И. Заһидуллин